Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе
Дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына конкурс нигезендә сайлап алу турында
ИГЪЛАН ИТӘ

**Казан шәһәре торак инспекциясенең торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты**

***Претендентларга төп таләпләр:***

- «Бакалавриат» дәрәҗәсеннән ким булмаган югары һөнәри белем (һөнәри белем алу юнәлешенә карата таләпләр, шулай ук дәүләт граждан хезмәте стажына һәм белгечлек буенча эш тәҗрибәсенә карата таләпләр куелмый);

***Казан шәһәре торак инспекциясенең торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлегенең әйдәп баручы белгеч-экспертының төп вазыйфалары:***

- торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү (коммуналь ресурслар) өчен исәп-хисаплар өлкәсендә законнардагы мәҗбүри таләпләр үтәлешен контрольдә тотуда катнаша;
- коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән) файдалану нормативлары составына, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән) файдалану нормативларын билгеләү шартларына һәм методларына, шулай ук коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән) файдалануның билгеләнгән норматив күләменең нигезле булу-булмавына карата таләпләр үтәлешенә контрольлек тәэмин итә;
- бүлеккә кергән материалларны (мәгълүматларны һ.б.ш.) (гамәлдәге законнар нигезендә), торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү (коммуналь ресурслар) өчен исәп-хисап өлкәсендәге мәсьәләләрне, шулай ук үз компетенциясе кысаларында нормативлар билгеләү мәсьәләләрен үз эченә алган физик затларның, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның мөрәҗәгатьләрен вакытында һәм тулысынча карап тикшерүне тәэмин итә;
- торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү (коммуналь ресурслар) өчен исәп-хисаплар, шулай ук нормативлар билгеләү өлкәсендә ТР Дәүләт торак инспекциясенең контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген камилләштерү эшен тәэмин итә;
- торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү (коммуналь ресурслар) өчен исәп-хисап өлкәсендәге административ хокук бозу турындагы эшләрне бүлек хезмәткәрләре тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кузгатуны оештыра;
- гражданнарның, башкарма хакимият органнарының, ведомстволарның һәм башка оешмаларның мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләү эшен оештыра.

***Эш вакыты:***

Биш көнлек эш атнасы:
Дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр,
төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Җомга: 8.30 сәгатьтән 16.15 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

***Хезмәт хакы:***

Сынау срогы чорында хезмәт хакы 17 500 сум тәшкил итә.

Сынау срогыннан соң хезмәт хакы 17 000 – 19 000 сум чикләрендә булырга мөмкин (класс чинын, дәүләт граждан хезмәте стажын исәпкә алып). Уртача еллык хезмәт хакы – 34 000.

***Гарантияләр:***

1. Тулы социаль пакет (Пенсия фондына, социаль иминият фондына, медицина иминияте фондына салымнар күчерү);
2. Дәүләт граждан хезмәткәрләрен ел саен диспансеризацияләү;
3. Дәүләт граждан хезмәткәрләренең гомерен ел саен иминиятләштерү;
4. Хезмәткә сәләтсезлек кәгазьләре түләнә;
5. Ел саен отпуск (30 календарь көне), эшләгән еллар өчен отпуск, уку өчен кирәкле отпуск (сессия), йөклелек һәм бала тудыру һәм 30 яшенә җиткәнчегә бала карау буенча отпуск бирелә.
6. Татарстан Республикасы бюджеты хисабына дәүләт граждан хезмәткәрләренең квалификациясен өч елга бер тапкыр күтәрү;
7. Карьера үсеше (вакантлы вазыйфаларны биләү буенча конкурс процедураларында катнашу яки югарыдагы вазыйфага кадрлар резервы);
8. 16 яшькә кадәрге балалары булган аналарга айга 1 мәртәбә эш буш вакыт бирелә;
9. Социаль ипотека буенча фатир алу мөмкинлеге (теркәлү буенча үз администрацияңдә чиратка басу).

***Эшкә алганда кирәкле документлар исемлеге:***

Теләк белдергән гражданин түбәндәге документларны һәм материалларны тапшыра:

1) шәхси гариза;
2) үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фоторәсемнәр (өч фото 2,5 х 3,0 һәм ике фото 4х6 – төсле, почмагы булмаган, ак фонлы, ялтыравыклы булмаган кәгазьдә);
3) паспорт күчермәсе (фото, прописка, 19 бит) яки аны алмаштыра торган документ күчермәсе;
4) мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсе;
5) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе (ИНН);
6) хәрби исәпкә алу документлары – хәрби бурычлылар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;
7) медицина полисы күчермәсе;
8) гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яисә аны узуга комачаулык итүче авыруларның булмавы турында документ (№001-ДС/у формасы «Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә керүгә яисә аны узуга комачаулаучы авыру булуы (булмавы) турында медицина учреждениесе бәяләмәсе»);

9) кирәкле һөнәри белем, эш стажы һәм квалификацияне раслый торган документлар:

а. хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш) яисә гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

б. һөнәри белем, өстәмә һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелүе турында документлар күчермәләре.

Нотариаль яки кадр хезмәтләре тарафыннан эш (хезмәт итү) урыны буенча таныкланган документларның күчермәләре;

10) керемнәр турында, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр;

11) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (3 данә);

12) типлаштырылган йөкләмә;

13) автобиография.

Документлар Казан шәһәре, Б.Красная урамы, 15/9 адресы буенча кабул ителә. Элемтә өчен телефон(факс): (843) 236-93-66.